**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

**егерме тугызынчы утырыш**

**28 июнь 2024 ел** **№129** **Теләче ав.**

**Теләче авыл җирлеге Советының 2018 елның 27нче апреле № 94 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, рәис урынбасарлары, аудиторлары депутатларның хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте,

1. Теләче авыл җирлеге Советының 2018 елның 27нче апреле № 94 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмә хакында» карарына (27.09.2018 №106, 20.12.2018 №120, 01.07.2019 №137, 18.09.2019 №140, 09.11.2022 №78, 16.12.2022 №81 карарлар редакциясендә), (алга таба текст буенча - карар), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 13323 сум итеп расларга.».

1.2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның һәм җирле үзидарә

органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 6, 11.5 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

1.2.1. «6. Теләче авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата бүләкләү билгеләнә. Айлык акчалата бүләкләү өчен чыгымнар күләме елына 14,12 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә торган нормативтан артып китә алмый.».

1.2.2. «11.5 Муниципаль хезмәткәргә хезмәт хакының 41 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү билгеләнә.».

1.3. Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге
Советының 2018 елның 27нче
апреле № 94 карарына 2
номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфа исемнәре | Айлык акчалата түләү, сум |
|---|---|
| | 11 төркем |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19991 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 14366 |

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Хаҗипов